ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2019 ел Баулы шәһәре №55

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
“Баулы муниципаль районы
муниципаль мәгариф оешмалары
хезмәткәрләренә хезмәт хакы
түләү шартлары турында”гы 2018
елның 25 июнендә кабул ителгән
248нче номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының “Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында”гы 2018 елның 25 июнендә кабул ителгән 248нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1нче “Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә” кушымтасында;

карарга 2нче “Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә" кушымтасында;

карарга 3нче “Баулы муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә" кушымтасында;

карарга 4нче "Баулы муниципаль районы мәгариф оешмалары гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең, җитәкчеләренең, белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә” кушымтасында

«база оклад», «вазыйфаи оклад» төшенчәләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт хакының база окладı (база вазыйфаи оклад), хезмәт хакының база ставкасы - тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче, һөнәри эшчәнлеген эшче яки хезмәткәр вазыйфасы буенча башкаручы дәүләт яки муниципаль учреждение хезмәткәренең минималь окладı (вазыйфаи оклад), хезмәт хакы ставкасы (компенсация, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча).

Оклад (вазыйфаи оклад) - календарь аена билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт вазыйфасын, бурычларын үтәгән өчен хезмәткәргә билгеләнгән күләмдә түләү (стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча)».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комтеты җитәкчесе И.И. Гозәеров